ГЛАВА
БОЛЬШЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ТИГӘНӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2021 с.Большие Тиганы № 2

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Зур Тигәнәле
авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 131 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Зур Тигәнәле авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 12 ноябренә 13:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан Зур Тигәнәле АМЙ бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал ур., 17 й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм салу (сатып алу, кучереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- Зур Тигәнәле авылында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьлары, исәпләү приборлары, таймерлар, СИП үткәргеч сатып алу, шартнамә буенча хезмәт хакы);

- җәйге чорда (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) территорияне каралту һәм үләннәрне чабу;

- каты көнкүреш калдыклары җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру һәм контейнерлар сатып алу (төзелеш материалы сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү шартнамә буенча);

- су башнясы өчен насослар сатып алу;

- тракторны карап тоту һәм ремонтлау (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

ӘЙЕ   ЮК».

4. Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы** **Н.Ө.Хаметшин**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БОЛЬШЕТИГАНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Р 05 11124/13
СОВЕТ БОЛЬШЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ